**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАРАТУН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2022 ел, 20 апрель №84

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 408-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге Советының 2020 елның 17 февралендәге 237 номерлы карары белән расланган Татарстан республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге генераль планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Чикләрне билгеләү гамәлләре» бүлегенең 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Җир кодексының 84 статьясындагы 1 өлеше нигезендә торак пунктларның чикләрен билгеләү, үзгәртү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Каратун авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Каратун авыл җирлеге Башлыгы Р.С. Исмәгыйлев**